ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр раслау хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 декабрендә
кабул ителде

1 статья

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керту турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр керту турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 21 сентябрендәге 1662 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турында төзелгән килешүләргә түбәндәге өстәмә килешүләрне расларга:

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы, 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүләргә 2022 елның 24 ноябрендәге 8/8/8 номерлы өстәмә килешүне әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә 2022 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы өстәмә килешүне әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миннеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 26 декабрь
№ 101-ТРЗ

«Федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына
бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау хакында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы, 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүләргә 8/8/8 номерлы ӨСТӘМӘ КИЛЕШҮ

Мәскәү шәһәре 2022 елның «24» ноябре

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2018 елның 5 июнендәге 712 номерлы боерыгы редакциясендә) нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В. Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керту турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 33 өлешенең 1 пункты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары белән расланган 2017 елда Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү кагыйдәләре нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы, 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүләргә 2020 елның 31 июлендәге 5/5/5 номерлы Өстәмә килешүгә (алга таба тиешенчә – килешүләр, Өстәмә килешү), 2020 елның 31 декабрендәге 6/6/6 һәм 7/7/7 номерлы Өстәмә килешүләр белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктның беренче абзацыннан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2022 елда бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурыч капланырга тиеш түгел. 2022 елда бюджет кредитлары буенча капланырга тиешле реструктуризацияләнгән бурыч 2029 елда каплана.»;

б) 5 пунктта:

«б» пунктчасында «акцияләрне сатудан һәм капиталда катнашуның башка рәвешләреннән, Россия Федерациясе субъекты милкендә булган кыйммәтле металларның һәм кыйммәтле ташларның дәүләт запасларын сатудан һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны, шул исәптән Россия Федерациясе субъектының Резерв фондындагы акчаларны, киметүдән кергән» сүзләрен «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 92^1 статьясындагы 2 пунктының өченче абзацында каралган» сүзләренә алмаштырырга;

«е» пунктчасында:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2022 елда бюджет кредитлары буенча бурычны каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын инженерлык эзләнүләрен башкаруга, проектлауга, проектлау документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм файдалануга тапшыруга, шулай ук «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2019 елның 2 декабрендәге 380-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 6 өлеше нигезендә билгеләнә торган яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга), Россия Федерациясе субъектларының федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен тәэмин итүгә, икътисад тармаклары үсешенә геосәяси һәм икътисадый вәзгыятьнең начараю йогынтысын булдырмауга бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә һәм коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм аның таралу зыяннарын бетерүгә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә җибәрү;»;

өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2023 – 2024 елларда бюджет кредитлары буенча бурычны каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын инженерлык эзләнүләрен башкаруга, проектлауга, проектлау документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм файдалануга тапшыруга, шулай ук «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2019 елның 2 декабрендәге 380-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 6 өлеше нигезендә билгеләнә торган яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга) җибәрү;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2022 елда 1 146 228 600 (бер миллиард йөз кырык алты миллион ике йөз егерме сигез мең алты йөз) сум»;

«ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) әлеге өстәмә килешүне Россия Федерациясе субъекты законы белән раслау (чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турындагы законнан тыш)».

2. Өстәмә килешүгә 1, 2, 3 нче кушымталар булган графикларны әлеге Өстәмә килешүгә 1, 2, 3 нче кушымталар нигезендәге редакциядә бәян итәргә.

3. Килешүләрнең һәм Өстәмә килешүнең әлеге өстәмә килешүдә кагылмаган һәм аңа каршы килми торган калган нигезләмәләре үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үз йөкләмәләрен раслыйлар.

4. Әлеге Өстәмә килешү килешүләрнең аерылгысыз өлеше булып тора, Яклар тарафыннан аны имзалаган көннән үз көченә керә һәм Яклар тарафыннан килешүләр буенча йөкләмәләрне тулысынча үтәүгә кадәр гамәлдә була.

Яклар Өстәмә килешүнең 5 пунктындагы «ж» пунктчасының (әлеге өстәмә килешү редакциясендә) гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип килештеләр.

5. Әлеге өстәмә килешү, кушымталарны да кертеп, һәр Як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 6 биттә төзелде.

Якларның урнашу урыны һәм адресы

Кредитор – Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Ильинка ур., 9, Мәскәү шәһәре, 109097.

Заемщик – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Ирек мәйданы, 1, Казан шәһәре, 420060.

Якларның имзалары

Кредитордан	**Заемщиктан**
Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары	Татарстан Республикасы Премьер-министры
_____ Л.В. Горнин	_____ А.В. Песошин
М.У.	М.У.

Федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына
Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын
өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында
2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы
килешүгә 2022 елның 24 ноябрендәге
8/8/8 номерлы Өстәмә килешүгә 1 нче кушымта

Реструктуризация үткәрелгән бурычны каплау
һәм кичектереп түләгән өчен процентларны түләү
графигы

Кире кайтару срогы		Реструктуризация үткәрелгән бурыч (сумнарда)	Реструктуризация үткәрелгән бурычны кире кайтару суммасы (сумнарда)	Кичектереп түләгән өчен процентлар (сумнарда)	Түләп бетерелгән, барлыгы (сумнарда)	Барлыгы түләргә (сумнарда)
2018 ел	30.11.2018	731 143 000,00	36 557 150,00	728 038,14	37 285 188,14	37 285 188,14
2019 ел	29.11.2019	694 585 850,00	36 557 150,00	691 380,84	37 248 530,84	37 248 530.84
2020 ел	30.11.2020	658 028 700,00	x	658 028,70	658 028,70	658 028,70
2021 ел	30.11.2021	658 028 700,00	36 557 150,00	654 923,85	37 212 073,85	37 212 073,85
2022 ел	30.11.2022	621 471 550,00	x	621 471,55	x	621 471,55
2023 ел	30.11.2023	621 471 550,00	36 557 150,00	618 366,69	x	37 175 516,69
2024 ел	29.11.2024	584 914 400,00	36 557 150,00	581 718,14	x	37 138 868,14
2025 ел	28.11.2025	548 357 250,00	102 360 020,00	539 102,79	x	102 899 122,79
2026 ел	30.11.2026	445 997 230,00	102 360 020,00	437 303,64	x	102 797 323,64
2027 ел	30.11.2027	343 637 210,00	102 360 020,00	334 943,62	x	102 694 963,62
2028 ел	30.11.2028	241 277 190,00	102 360 020,00	232 607,35	x	102 592 627,35
2029 ел	30.11.2029	138 917 170,00	138 917 170,00	127 118,73	x	139 044 288,73
Барлыгы	x	x	**731 143 000,00**	**6 225 004,04**	**112 403 821,53**	**737 368 004,04**

Якларның имзалары

Кредитордан

Россия Федерациясе
Финанс министрының
беренче урынбасары

_____ Л.В. Горнин

М.У.

Заемщиктан

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

_____ А.В. Песошин

М.У.

Федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына
Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын
өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында
2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы
килешүгә 2022 елның 24 ноябрендәге
8/8/8 номерлы Өстәмә килешүгә 2 нче кушымта

Реструктуризация үткәрелгән бурычны каплау
һәм кичектереп түләгән өчен процентларны түләү
графигы

Кире кайтару срогы		Реструктуризация үткәрелгән бурыч (сумнарда)	Реструктуризация үткәрелгән бурычны кире кайтару суммасы (сумнарда)	Кичектереп түләгән өчен процентлар (сумнарда)	Түләп бетерелгән, барлыгы (сумнарда)	Барлыгы түләргә (сумнарда)
2018 ел	30.11.2018	4 853 066 000,00	242 653 300,00	4 832 457,09	247 485 757,09	247 485 757,09
2019 ел	29.11.2019	4 610 412 700,00	242 653 300,00	4 589 138,98	247 242 438,98	247 242 438,98
2020 ел	30.11.2020	4 367 759 400,00	x	4 367 759,40	4 367 759,40	4 367 759,40
2021 ел	30.11.2021	4 367 759 400,00	242 653 300,00	4 347 150,49	247 000 450,49	247 000 450,49
2022 ел	30.11.2022	4 125 106 100,00	x	4 125 106,10	x	4 125 106,10
2023 ел	30.11.2023	4 125 106 100,00	242 653 300,00	4 104 497,19	x	246 757 797,19
2024 ел	29.11.2024	3 882 452 800,00	242 653 300,00	3 861 237,21	x	246 514 537,21
2025 ел	28.11.2025	3 639 799 500,00	679 429 240,00	3 578 371,65	x	683 007 611,65
2026 ел	30.11.2026	2 960 370 260,00	679 429 240,00	2 902 665,31	x	682 331 905,31
2027 ел	30.11.2027	2 280 941 020,00	679 429 240,00	2 223 236,07	x	681 652 476,07
2028 ел	30.11.2028	1 601 511 780,00	679 429 240,00	1 543 964,50	x	680 973 204,50
2029 ел	30.11.2029	922 082 540,00	922 082 540,00	843 768,68	x	922 926 308,68
Барлыгы	x	x	**4 853 066 000,00**	**41 319 352,67**	**746 096 405,96**	**4 894 385 352,67**

Якларның имзалары

Кредитордан

Россия Федерациясе
финанс министрының
беренче урынбасары

_____ Л.В. Горнин

М.У.

Заемщиктан

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

_____ А.В. Песошин

М.У.

Федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына
Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын
өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында
2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы
килешүгә 2022 елның 24 ноябрендәге
8/8/8 номерлы Өстәмә килешүгә 3 нче кушымта

Реструктуризация үткәрелгән бурычны каплау
һәм кичектереп түләгән өчен процентларны түләү
графигы

Кире кайтару срогы		Реструктуризация үткәрелгән бурыч (сумнарда)	Реструктуризация үткәрелгән бурычны кире кайтару суммасы (сумнарда)	Кичектереп түләгән өчен процентлар (сумнарда)	Түләп бетерелгән, барлыгы (сумнарда)	Барлыгы түләргә (сумнарда)
2018 ел	30.11.2018	146 934 000,00	7 346 700,00	146 310,03	7 493 010,03	7 493 010,03
2019 ел	29.11.2019	139 587 300,00	7 346 700,00	138 943,21	7 485 643,21	7 485 643,21
2020 ел	30.11.2020	132 240 600,00	x	132 240,60	132 240,60	132 240,60
2021 ел	30.11.2021	132 240 600,00	7 346 700,00	131 616,64	7 478 316,64	7 478 316,64
2022 ел	30.11.2022	124 893 900,00	x	124 893,90	x	124 893,90
2023 ел	30.11.2023	124 893 900,00	7 346 700,00	124 269,93	x	7 470 969,93
2024 ел	29.11.2024	117 547 200,00	7 346 700,00	116 904,87	x	7 463 604,87
2025 ел	28.11.2025	110 200 500,00	20 570 760,00	108 340,68	x	20 679 100,68
2026 ел	30.11.2026	89 629 740,00	20 570 760,00	87 882,63	x	20 658 642,63
2027 ел	30.11.2027	69 058 980,00	20 570 760,00	67 311,88	x	20 638 071,88
2028 ел	30.11.2028	48 488 220,00	20 570 760,00	46 745,88	x	20 617 505,88
2029 ел	30.11.2029	27 917 460,00	27 917 460,00	25 546,39	x	27 943 006,39
Барлыгы	x	x	**146 934 000,00**	**1 251 006,64**	**22 589 210,48**	**148 185 006,64**

Якларның имзалары

Кредитордан

Россия Федерациясе
финанс министрының
беренче урынбасары

_____ Л.В. Горнин

М.У.

Заемщиктан

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

_____ А.В. Песошин

М.У.

«Федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына
бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау хакында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә
2 номерлы ӨСТӘМӘ КИЛЕШҮ

Мәскәү шәһәре 2022 елның «24» ноябре

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2020 елның 10 декабрендәге 1088 номерлы боерыгы нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В. Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керту турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 33 өлешенең 1 пункты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 июнендәге 1029 номерлы карары белән расланган 2021 елда Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү кагыйдәләре нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә 2021 елның 1 июлендәге 1 номерлы Өстәмә килешүгә (алга таба – 1 номерлы Өстәмә килешү) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктның икенче абзацыннан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2022 елда бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурыч капланмый. 2022 елда капланырга тиешле бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурыч 2029 елда каплана.»;

б) 4 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) 2021 – 2024 елларда 2021 елда бюджет кредитлары буенча бурычны каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын инженерлык эзләнүләрен башкаруга, проектлауга, проектлау документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм файдалануга тапшыруга, шулай ук «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 өлеше нигезендә билгеләнә торган яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга), 2022 елда аларны Россия Федерациясе субъектларының федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен тәэмин итүгә, икътисад тармаклары үсешенә геосәяси һәм икътисадый вәзгыятьнең начараю йогынтысын булдырмауга бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә һәм коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм аның таралу зыяннарын бетерүгә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә җибәрү мөмкинлеген дә кертеп, җибәрү.

2022 елда бюджет кредитлары буенча бурычны каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары 2022 елда инженерлык эзләнүләрен башкаруга, проектлауга, проектлау документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм файдалануга тапшыруга, шулай ук яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга), Россия Федерациясе субъектларының федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен тәэмин итүгә, икътисад тармаклары үсешенә геосәяси һәм икътисадый вәзгыятьнең начараю йогынтысын булдырмауга бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә һәм коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм аның таралу зыяннарын бетерүгә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә җибәрелә.

Әлеге пунктчада каралган максатларга җибәрелергә тиешле Россия Федерациясе субъекты бюджетының азат ителә торган акчалары күләме Килешүгә кушымта булган бюджет кредиты буенча бурычны түләү графигы нигезендә билгеләнә торган бюджет кредиты буенча реструктуризацияләнгән бурычны каплауның күләме һәм 2021 елда бюджет кредиты буенча реструктуризацияләнгән бурычны каплауның Кагыйдәләрнең 8 пункты нигезендә билгеләнә торган күләме арасындагы аерма буларак исәпләнә һәм 1 960 350 650 (бер миллиард тугыз йөз алтмыш миллион өч йөз илле мең алты йөз илле) сум, шул исәптән 2022 елда 103 176 350 (бер йөз миллион йөз җитмеш алты мең өч йөз илле) сум тәшкил итә;»;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) әлеге Өстәмә килешүне Россия Федерациясе субъекты законы белән раслау (чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турындагы законнан тыш)»;

түбәндәге эчтәлекле «в[1]» пунктчасы өстәргә:

«в[1]) 2022 елның 1 сентябренә бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме, 2022 елның 1 сентябренә кире кайтарылмый торган кертемнәрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәренең гомуми күләменнән 100 проценттан артыгын, бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме 2023 елның 1 гыйнварына, 2024 елның 1 гыйнварына, 2025 елның 1 гыйнварына, 2026 елның 1 гыйнварына, 2027 елның 1 гыйнварына, 2028 елның 1 гыйнварына, 2029 елның 1 гыйнварына һәм 2030 елның 1 гыйнварына, тиешенчә 2022 – 2029 елларга кире кайтарылмый торган акчаларны исәпкә алмыйча, Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәренең гомуми күләменнән 80 проценттан артыгын тәшкил иткән Заемщик тарафыннан Федераль казначылыкның территориаль органы һәм Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы арасында төзелгән Россия Федерациясе субъектының чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә беренчел чыгымнар режимын куллану турындагы килешү нигезендә Россия Федерациясе субъекты бюджетының үтәлешен оештыруны тәэмин итү, килешүгә түбәндәге нигезләмәләр керә:

Федераль казначылыкның территориаль органына – бюджет үтәлеше буенча операцияләрне исәпкә алу өчен билгеләнгән шәхси счетлар ачу һәм аларны алып бару, Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә һәм алучыларга һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына (администраторларына) бюджет ассигнованиеләрен, бюджет йөкләмәләре лимитларын, финанслауның иң чик күләмнәрен Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә һәм алучыларга һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына (администраторларына) җиткерү, бюджет йөкләмәләрен һәм акчалата йөкләмәләрне исәпкә алу һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләүгә бәйле операцияләргә санкцияләр бирү буенча Россия Федерациясе субъектының финанс органы функцияләрен тапшыру турында;

акчаларны исәптән төшерү чиратлылыгы турында, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган һәм шул исәптән бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнары һәм башка гавами норматив йөкләмәләргә чыгымнар кергән Россия Федерациясе субъекты бюджетының беренчел чыгымнары исемлеге;

Россия Федерациясе субъектының беренчел чыгымнар исемлегенә кертелгән чыгым йөкләмәләре буенча срогы чыккан кредит бурычы булганда, Россия Федерациясе субъектының беренчел чыгымнар исемлегенә кертелмәгән чыгым йөкләмәләре буенча акча күчерүләргә юл куелмау турында;

в) 4 пунктның «г» пунктчасында « әлеге пунктның «а» – «в» пунктчаларында» сүзләрен «әлеге пунктның «а» – «в[1]» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2024 ел йомгаклары буенча Заемщик тарафыннан Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләрне үтәүне бәяләгәндә азат ителә торган акчаларны инженерлык эзләнүләрен башкаруга, проектлауга, проектлау документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм файдалануга тапшыруга, шулай ук яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга) җибәрү өлешендә Россия Федерациясе субъекты тарафыннан Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган максатларга җибәрелергә тиешле Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары, 2022 елда аларны Россия Федерациясе субъектларының федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен тәэмин итүгә, икътисад тармаклары үсешенә геосәяси һәм икътисадый вәзгыятьнең начараю йогынтысын булдырмауга бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә һәм коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм аның таралу зыяннарын бетерүгә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә җибәрү мөмкинлеген дә кертеп, Россия Федерациясе субъекты бюджетының 2021 – 2024 елларда күрсәтелгән максатларга җибәрелгән акчалар күләменнән чыгып билгеләнә.

2021 – 2024 елларның йомгаклары буенча Заемщик тарафыннан Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләр үтәлмәгәндә, Заемщик 2025 елда график нигезендә реструктуризация үткәрелгән бурычны һәм кичектереп түләгән өчен процентларны каплый, шулай ук 2025 – 2027 елларда вакытыннан алда, ел саен тигез өлешләрдә, бурычны вакытыннан алда каплау каралган графикта билгеләнгән срокта, 2022 елда азат ителә торган акчаларны коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм аның таралу зыяннарын бетерүгә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә җибәрү мөмкинлеген дә кертеп, инженерлык эзләнүләрен башкаруга, проектлауга, проектлау документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм файдалануга тапшыруга, шулай ук яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга) җибәрелергә мондый акчалар күләмендә каплый.»;

җиденче абзацта «10 пунктындагы «в» һәм «е» пунктчаларын» сүзләрен «10 пунктындагы «в», «д[1]» һәм «е» пунктчаларын» сүзләренә алмаштырырга.

2. Килешүгә кушымта булган графикны әлеге Өстәмә килешүгә кушымта нигезендәге редакциядә бәян итәргә.

3. Килешүнең әлеге Өстәмә килешүдә кагылмаган һәм аңа каршы килми торган калган нигезләмәләре үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үз йөкләмәләрен раслыйлар.

4. Әлеге Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора, Яклар

тарафыннан аны имзалаган көннән үз көченә керә һәм Яклар тарафыннан Килешү буенча йөкләмәләрне тулысынча үтәүгә кадәр гамәлдә була.

Яклар 1 номерлы Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «б» пунктчасының (әлеге Өстәмә килешү редакциясендә) гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип килештеләр.

5. Әлеге Өстәмә килешү, кушымтаны да кертеп, һәр Як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 6 биттә төзелде.

Якларның урнашу урыны һәм адресы

Кредитор – Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Ильинка ур., 9, Мәскәү шәһәре, 109097.

Заемщик – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Ирек мәйданы, 1, Казан шәһәре, 420060.

Якларның имзалары

Кредитордан

Россия Федерациясе
Финанс министрының
беренче урынбасары

_____ Л.В. Горнин

М.У.

Заемщиктан

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

_____ А.В. Песошин

М.У.

Россия Федерациясе субъектлары
бюджетлары счетларында калган
акчаларны тулыландыруга бюджет
кредитларын каплау өчен
федераль бюджеттан Татарстан
Республикасы бюджетына бюджет
кредиты бирү турында 2020 елның
14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы
килешүгә 2022 елның 24 ноябрендәге
2 номерлы Өстәмә килешүгә кушымта

Реструктуризация үткәрелгән бурычны каплау
һәм кичектереп түләгән өчен процентларны түләү
графигы

Кире кайтару срогы		Реструктуризация үткәрелгән бурыч (сумнарда)	Реструктуризация үткәрелгән бурычны кире кайтару суммасы (сумнарда)	Кичектереп түләгән өчен процентлар (сумнарда)	Барлыгы түләргә (сумнарда)
2021 ел	30.11.2021	2 063 527 000,00	103 176 350,00	1 025 827,32	104 202 177,32
2022 ел	30.11.2022	1 960 350 650,00	x	1 960 350,65	1 960 350,65
2023 ел	30.11.2023	1 960 350 650,00	103 176 350,00	1 951 587,73	105 127 937,73
2024 ел	29.11.2024	1 857 174 300,00	103 176 350,00	1 848 153,41	105 024 503,41
2025 ел	28.11.2025	1 753 997 950,00	330 164 320,00	1 724 147,47	331 888 467,47
2026 ел	30.11.2026	1 423 833 630,00	330 164 320,00	1 395 792,27	331 560 112,27
2027 ел	30.11.2027	1 093 669 310,00	330 164 320,00	1 065 627,96	331 229 947,96
2028 ел	30.11.2028	763 504 990,00	330 164 320,00	735 540,25	330 899 860,25
2029 ел	30.11.2029	433 340 670,00	433 340 670,00	396 536,39	433 737 206,39
Барлыгы	x	x	**2 063 527 000,00**	**12 103 563,45**	**2 075 630 563,45**

Якларның имзалары

Кредитордан

Россия Федерациясе
Финанс министрының
беренче урынбасары

_____ Л.В. Горнин

М.У.

Заемщиктан

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

_____ А.В. Песошин

М.У.